**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“29” ноябрь 2020 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Комыргуҗа торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа авылы территориясендә 2021 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Комыргуҗа авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- Комыргуҗа авылы зиратын чистарту (үлән чабу );
- Кышкы чорда кабер казу өчен электр чүкече (отбойный молоток) сатып алу.
- Комыргуҗа авылында үлән чабу, транспорт хезмәтләре күрсәтү;
- Татарстан урамында ясалма тигезсезлекләр урнаштыру, тиешле юл билгеләре белән билгеләнгән.
- Барлык комплектлау җайланмалары булган мотопомпалар сатып алу;
- Автономияле резерв чыганагы сатып алу (генератор);
- Комыргуҗа елгасы янындагы юлга вак таш сатып алу, транспорт хезмәте күрсәтү (елга янгынга каршы су чыганагы булып тора).

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегенең Комыргуҗа авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Комыргуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлеге Комыргуҗа авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Комыргуҗа авыл җирлеге башлыгы Низамиев Ф.Ф.